ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«18 » март 2022 ел № 39-р

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендәге иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениеләре һәм аларның хезмәткәрләре тарафыннан акчалата бүләкләү конкурсында җиңүчеләр турында

Россия Федерациясе Президентының «Авыл җирлекләре территорияләрендәге муниципаль мәдәният учреждениеләренә һәм аларның хезмәткәрләренә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2012 елның 28 июлендәге 1062 номерлы Указын, «Авыл җирлекләре территорияләрендәге иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениеләренә һәм аларның хезмәткәрләренә дәүләт ярдәме чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 17 сентябрендәге 664 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләре территорияләрендәге иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениеләре һәм аларның хезмәткәрләре тарафыннан акчалата бүләкләү конкурсы турында» 2013 елның 27 сентябрендәге 811 од номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләре территорияләрендәге иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениеләре һәм аларның хезмәткәрләре тарафыннан акчалата бүләкләү конкурсында җиңүчеләр турында» 2022 елның 15 мартындагы 149од номерлы боерыгы нигезендә, "Татарстан Республикасы авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениеләре һәм аларның хезмәткәрләре тарафыннан акчалата бүләк алучыларны билгеләү буенча конкурс комиссиясе утырышының 2002 елның 05 мартындагы 18 пр номерлы беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2022 елның 16 мартындагы 1982-07 номерлы хатын исәпкә алып:

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендәге иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениеләренә һәм аларның хезмәткәрләренә «Татарстан Республикасы авыл җирлеге территориясендә урнашкан иң яхшы китапханә», «Татарстан Республикасы авыл җирлеге территориясендә урнашкан иң яхшы мәдәни-ял итү тибындагы учреждение», «Татарстан Республикасы авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәдәни-ял итү тибындагы иң яхшы учреждение»,

«Татарстан Республикасы авыл җирлекләре территорияләрендәге муниципаль мәдәният учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләре» номинацияләре буенча акчалата бүләкләү конкурсында җиңүчеләрне игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты арасында бюджетара трансферларны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетына тапшыру турында килешүләр төзүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына тәкъдим итәргә:

кушымта нигезендә иң яхшы авыл мәдәният учреждениеләре өчен 200,0 мең сум күләмендә акча һәм авыл мәдәният учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләре өчен 50,0 мең сум күләмендә акча тәэмин итәргә;

акчалардан максатчан файдалануны тикшереп торуны тәэмин итәргә.

4. Беркетергә:

авыл мәдәният учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен «мәдәният тармагына ярдәм итү (авыл мәдәният учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә дәүләт ярдәме күрсәтү)»22-55190-001001 максатчан коды;

иң яхшы авыл мәдәният учреждениеләренә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен «мәдәният тармагына ярдәм итү (иң яхшы авыл мәдәният учреждениеләренә дәүләт ярдәме күрсәтү)» 22-55190-0000-01002 максатчан коды.

5. Әлеге күрсәтмәне Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**